# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Алга торак пунктында
2025 елда үзара салым кертү турында

**15.11.2024 ел** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 05 ноябрендәге 9 номерлы “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Алга авылында 2025 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турындагы” карары нигезендә 2024 елның 15 ноябрендә 8.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

«Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, 2025 елда үзара салым акчаларын кертүгә, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Алга торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау.

2) автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);

3) Халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзеклзү (корыган агачларны кисү) ?

3. Әлеге карарны Саклаубаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина